# ПРОБЛЕМАЛЫ УКУ-УКЫТУ ПРОЦЕССЫ НИЧЕК ОЕШТЫРЫЛА

**М. МӘХМҮТОВ**,
СССР Педагогия фәннәре академиясенең член-корреспонденты

Ун елдан артык инде педагоглар арасында уку-укыту процессын активлаштыру турында җитди сөйләшү бара. Бу сөйләшүнең темасы әһәмиятле һәм кызыклы: балаларның фикерләү сәләтен үстерә торган уку-укыту алымнарын һәм методларын ничек табарга?

Соңгы елларда уку-укыту процессын активлаштыру проблемасын хәл итү юллары беркадәр ачыклана төште. Моңа, беренчедән, укытуның яңа эчтәлеге һәм, икенчедән, алдынгы педагогик тәҗрибәне тарату һәм гамәлгә кертү ярдәм итте.

Алдынгы тәҗрибә уку-укыту процессы активлыгына ничек тәэсир итте соң? Укучыларның активлыгын үстерү юлларын эзләү барышында укытучыларның, өлешчә, Казан мәктәпләре укытучыларының, уртак, күмәк фикере дәрес төзелешенең яңа структурасын, укытуны тормыш белән бәйләүнең алымнарын эзләп тапты, уку-укыту процессында укучыларның мөстәкыйль эшләренең тоткан урыны яңача билгеләнде. Яңа белемнәрне үзләштергәндә танып-белү мәсьәләләренең урыны һәм роле ачыкланды, укытуны индивидуальләштерү төшенчәсе үстерелде һәм педагогик тасавыр (ягъни кайсы укыту алымы укучының теге яки бу фикерләү алымын тудырачагын алдан күрү) принциплары эшкәртелде.

Күп кенә укытучыларның дәресләре хәзер күңелсез һәм ялыктыргыч сорау-җа-вaптан түгел, бәлки үткәнне кабатлау өчен мөстәкыйль эшләр бирүдән башлана икән, әгәр укытучы дәрестә коры аңлату белән генә чикләнмичә, бәлки танып-белү мәсьәләләрен чиштерү юлы белән укучыларның үзләренә белемнең асылына төшенергә мөмкинлек бирә икән, бу инде укытучы балаларның фикерләү сәләтен үстерүче нәтиҗәле дәрес үткәрә дигән сүз.

Әнә шулай алдынгы тәҗрибә традицион уку-укыту процессына зур үзгәрешләр кертте. Әмма болар барысы да тәҗрибә юлы белән, укытучыларның тырышлыгы һәм таланты белән табылды. Әгәр шулай икән, хәзерге заман җәмгыятенең әһәмиятле бурычларын үтәүдә педагогика фәненең урыны нидән гыйбарәт соң?

Педагог галимнәрнең хезмәте барыннан да элек шунда, алар мәктәп укытучыларының методик табышларын вакытында күрә һәм аларга дөрес бәя бирә алдылар. Алар алдынгы педагогик тәҗрибәне гомумиләштерделәр һәм теоретик

нигезләделәр, дәрес теориясен, мөстәкыйль эшләр теориясен һ. б. үстерделәр. Унлаган педагогик журналлар иске төшенчәләрне яңача аңлатып, айдан-айга, елдан-елга мәктәпләргә җиткереп тордылар. Нәтиҗәдә күңел эзләнүе, интуиция юлы белән генә табылганнарны укытучылар аңлы рәвештә куллана башладылар. Шуның аркасында алдынгы педагоглар гына куллана торган методлар һәм алымнар хәзер илебезнең төрле почмакларындагы меңләгән укытучыларның уртак хәзинәсенә әйләнде.

Бүгенге мәктәп укучыларны «фикерләргә өйрәтү» бурычын үтәп җиткерәме? Юк, бөтенләй үк үтәп җиткерми әле. Теоретик яктан гомумиләштерелгән алдынгы педагогик тәҗрибәне мәктәп практикасына кертү укучыларның уку-танып-белү эшчзнлеген активлаштыруга тик нигез генә салды. Укучыларның фикерләү сәләтен үстерү буенча барлык укытучылар да уңышлы эшләсен һәм моңа ирешсен өчен, алармы укыту процессын активлаштыруның аерым алымнары белән генә түгел, бәлки бербөтен теория белән коралландырасы, аларның барсын да **яңа дидактик системаның** асылына тирәнтен төшендерәсе бар. **Бу яңа система проблемалы укыту** дип атала. Проблемалы укыту исә үзе алдынгы педагогик тәҗрибәне теоретик нигезләүдә галимнәребезнең хәзерге заман философия, психология һәм кибернетика фәннәре казанышларын файдалanулары нәтиҗәсе буларак барлыкка килде. Димәк, укытуның яңа теориясе — фәнни казанышлар белән алдынгы тәҗрибәнең бергә кушылуы ул.

Укытуның яңа төре, тибы нигезенә дидактика (уку-укыту теориясе) тарафыннан элек исәпкә алынмаган нинди закончалыклар салынды соң? Беренче нәүбәттә, «проблемалы ситуациямнең психологик закончалыклы булуы һәм фән методларының нигезен тәшкил итүче танып-белү теориясенең «тикшеренү принцибы» салынды.

Психология фәне, нинди дә булса берәр проблема белән очрашканда гына, проблемалы ситуация туган шартларда гына кеше уйлый-фикерли башлый, дип өйрәтә. Шунлыктан **проблемалы уку-укытуның нигезекг** укытучы тарафыннан системалы рәвештә һәм **алдан уйлап тудырылган** проблемалы) **ситуация тәшкил итә.** Танып-белү процессының барлык этапларын, һич югында бер генә этабын гына булса да, мөстәкыйль рәвештә үтәгән очракта гына укучыларның танып-белү эшчәнлеге мөстәкыйль булып исәпләнә. Бу ни дигән сүз соң? Бу:

а) хасил булган ситуацияне укучылар үзләре анализлаганда һәм проблеманы үзләре тәгъбирләгәндә, ягъни туган читенлекнең асылын үзләре сөйләп бирә алганда гына ул мөстәкыйль танып-белү эшчәнлеге була ала, дигән сүз.

Мәсәлән, 1 класс укучылары на түбәндәге мисал бирелгән ди: 2 + 6 = ?

Кушу һәм алу гамәлләрен инде белгәнлектән, алар бу мисалны җиңел чишәләр (2 + 6 = 8). Укытучы яңа мисал бирә: x + 6 = 9. Укучылар моны шунда ук чишә алмыйлар, кыенсыналар (проблемалы ситуация туа).

Укытучы: Мисалда нәрсә билгесез? Сорауга җавап итеп укучылар үз проблемаларын тәгъбир итәләр:

— Беренче кушылучы билгесез,— диләр алар.

б) Проблеманы хәл итүнең (укучылар үзләре яки укытучы тәгъбир иткән проблеманы) ысулларын укучылар үзләре фараз итәләр[1], ягъни хәл итүнең төрле вариантларын (юлларын) эзлиләр.

Шуннан соң югарыда тәгъбирләнгән проблеманы хәл итүнең ысуллары табыла. «9 га 6 ны кушарга кирәк»,— ди укучыларның берсе. «Юк, билгесез кушылучыны табарга кирәк»,— ди икенчесе. Шулай итеп, проблеманы хәл итүнең фараз ителгән ике ысулы барлыкка килде.

в) Укытучы куйган (әйткән) фаразны укучылар үзләре гипотеза итеп нигезлиләр.

г) Укытучы куйган гипотезаны укучылар үзләре исбат итәләр һәм проблеманың дөрес хәл ителүен тикшерәләр.

Өченче укучы мисалны чишүнең өченче юлын әйтә: «Юк, кушарга кирәкми, 9 дан 6 ны алырга кирәк, чөнки 9 — ике кушылучының суммасы ул»,— ди. Биредә фараз итүнең өченче юлы табылды гына түгел, бәлки ул гипотеза булып нигезләнде дә.

Хәзер моны алу юлы белән исбатлыйсы һәм проблеманы хәл итүнең дөреслеген тикшерәсе генә калды. 9 - 6 = 3; 3 + 6 = 9.

Укучылар танып-белү процессы этапларын ничаклы күбрәк мөстәкыйль рәвештә узсалар, аларның танып-белү мөстәкыйльлеге шул кадәр югарырак була. Аның иң югары дәрәҗәсенә укучылар хасил булган ситуациядә проблеманы үзләре тәгъбирләгәндә, фараз итүнең вариантларын үзләре чамалаганда, гипотезаны үзләре нигезләп, аны исбатлаганда һәм проблеманы хәл итүнең

[1] Бу мәкаләдә фараз — предположение, «тәгъбир — формулировка, танып-белү мәсьәләсе — познавательная задача, тасавыр — предвидение, бирем — задание, решение проблемы — проблеманы хәл итү, решение задачи — мәсьәләне чишү һ. б. ш. терминнар алынды. Психология фәне, укучының үсеше аның үз эшчәнлеге процессында бара, дип раслый. Бу закончалык проблемалы укытуның нигезендә ята.

дөреслеген үзләре тапканда гына ире-шелә. Билгеле, укучының барлык шушы этапларны читләтеп-чамалап та, кинәт төшенеп тә проблеманы хәл итү юлын таба алуы мөмкин. Бу шулай ук фикерләү активлыгының күрсәткече булып тора.

Болар һәммәсе — кешенең фикерләү эшчәнлеге активлыгының психологик закончалыклары. Әмма уку яки мөстәкыйль эшләр процессында укучының уку-танып-белү эшчәнлеген оештыру укытучыдан теге яки бу методларның ролен һәм урынын төгәл аңлавын һәм белеп куллануын таләп итә. Чыннан да, «проблемалы ситуация тудыру» дигән «сихерле» төшенчәдән нәрсәне аңларга соң? Дидактика теленә күчерсәк, ул болай була, укытучы укучылар алдына кинәт кенә җавап биреп булмый торган сорау куя (чөнки аларның җавап бирер өчен ниндидер күләмдә белемнәре җитеп бетми әле).

Укытучы класска укучылар бөтенләй җавап бирә алмаслык сорау да куя ала. Мәсәлән, ул X класс укучыларына таныш булган «Яктылыкның корпускуляр теориясе нәрсәне аңлата?» дигән сорауны VII класс укучыларына бирсә, алар моңа, билгеле, җавап таба алмаячаклар.

Күренгәнчә, иң катлаулы сорау да кайвакыт укучыда актив фикерләү эшчәнлеге тудырмый икән. Бөтен хикмәт шунда, укытучы класска бирә торган сорауга (биремгә) укучылар шушы минутта ук җавап табарга кыенсынсалар да, әмма ул сорау алар мөстәкыйль рәвештә җавап табарлык дәрәҗәдә генә читен булырга тиеш. Икенче төрле әйтсәк, укучыларда вакытлы читенлек (проблемалы ситуация) тудырган, әмма мөстәкыйль фикерләү барышында җавап бирергә (проблеманы хәл итәргә) укучыларның көче җиткән сорау гына проблемалы сорау була ала.

Проблемалы сорауга җавап табуга нинди юл белән ирешелә соң? Моңа укучылар, нигездә, элек үзләре алган белемнәрдән файдалану, бирелгән шартларга, сорауның, биремнең, мәсьәләнең таләпләренә анализ ясау, мөстәкыйль рәвештә яңа кагыйдә чыгару, теорема һәм законны нигезләү өчен фикери эзләнү (умственный поиск) алымнары куллану юлы белән ирешәләр.

Югарыдагы мисалда балалар аны чишүнең шартына анализ ясап, үзләре мөстәкыйль рәвештә: «Билгесез кушылучыны табу өчен суммадан билгеле кушылучыны алырга кирәк»,— дигән нәтиҗәгә килделәр. Укучыларның яңа белемне мөстәкыйль рәвештә үзләштерүләре менә шушы була инде.

Яңа белемнәрнең билгеле бер өлешен (никадәр күбрәк булса, шулкадәр яхшырак) укучылар, ятлау, зиһенгә алу юлы белән генә түгел, бәлки фикерләү юлы белән дә үзләштерсеннәр өчен, уку-укыту процессын ничек һәм нинди юллар белән оештырырга? Безнең көннәрдә күпчелек педагогларны борчый торган төп

мәсьәлә, безнеңчә, әнә шул.

Аңлашыла ки, бу үзе зур бер фән, чөнки проблемалы уку-укытуны хәзер дидактик система дип атыйлар. Проблемалы уку-укыту процессын оештыруның төп үзенчәлекләре нидән гыйбарәт? Хәзер шушы сорауга кыскача гына булса да җавап эзләп карыйк.

Проблемалы уку-укытуны оештыруның конкрет юлларын күз алдына китерү өчен, психологик-дидактик закончалыкларны белүдән тыш, бу процессны дидактиканың төшенчәләре җирлегендә карау зарури. Дидактиканың иң әһәмиятле төшенчәләренә уку-укыту процессын оештыруның һәм аны идарә итүнең **алымнары** (приемы), **методлары, ысуллары** (способы) һәм **формалары** керә.

## УКУ-УКЫТУ АЛЫМНАРЫ ҺӘМ МЕТОДЛАРЫ ТУРЫНДА

Мәктәп баланы фикерләргә өйрәтергә тиеш. Моңа ирешүдә иң дөрес юл — уку-укыту методларын фән методларына якынайту, төгәлрәге, уку-укыту процессын фәнни тикшеренү процессы законнарын исәпкә алып оештыру.

Кешенең иҗади танып-белү эшчәнлеге закончалыкларына таянучы проблемалы уку-укытуны оештыруның алымнары, методлары һәм ысуллары нидән гыйбарәт соң? Яңа тип уку-укытуны уңышлы алып бару өчен, бу терминнарны элеккечә төшенү генә җитәме? Юк, җитми.

Тормыш уку-укыту методларының эчтәлеген һәм аларны классификацияләүне традицион аңлауның проблемалы уку-укытуны оештыру бурычларына туры килеп җитмәвен күрсәтте. Ни өчен шулай? — дигән сорау туа.

Мисалга «Уку-укыту методы» (метод обучения) дигән терминны гына алып карыйк. Ул нинди төшенчәне чагылдыра? «Уку-укыту» дигәннән теге яки бу педагог нәрсәне аңласа, ул шуны чагылдыра. Әгәр педагог бу процессны, укытучы һәм укучы эшчәнлеге, дип караса, ул вакытта «Уку-укыту методы» дигән термин бер үк вакытта икесенең дә (укытучының да, укучының да) эшчәнлеген, ягъни конкрет эш-чәнлекне түгел, бәлки гомумиләштерелгән эшчәнлекме чагылдыра.

Әгәр педагог «Уку-укыту процессы» дигәннән укытучының гына эшчәнлеген аңласа, ул вакытта «Уку-укыту методы» термины укытучыга гына карый. Хәер, соңгысы уку-укыту процессының асылын аңлауның иң таралган төре булып тора. Педагогик әдәбиятта, укучы педагогик йогынты ясау объекты гына түгел, бәлки субъект та, дигән фикернең киң тарала башлавы очраклы хәл түгел!

Чынлап та, укучы педагогик йогынты ясау объекты гына түгел, бәлки уку-укыту процессы субъекты да, җан иясе дә, фикер иясе дә ул. Укучы — уку хезмәте белән

шөгыльләнүче эшлекле (деятель) ул, дип тану гына җитәме соң? Юк, бу гына җитми! Әгәр укучыны эшлекле дип таныйбыз икән, уку — шул ук хезмәт икән, ул чагында, димәк, баланың эшчәнлек процессы, уку хезмәте процессы да булырга тиеш. Дөрес, моны берәү дә инкарь итми, әгәр бу шулай икән, димәк, уку-укыту ике яклы процесс була, ул өйрәтү (укыту) һәм өйрәнү (уку) процессларыннан тора. Моңа кадәр өйрәнү процессы турында фикер йөртү шушы урында тәмамлана, аның закончалыклары, укучының уку-өйрәнү методлары һәм алымнары турында бер сүз дә әйтелми иде.

Проблемалы уку-укыту, киресенчә, укучының танып-белү эшчәнлеген активлаштыруны беренче планга куя. Шунлыктан «мәктәп баласының укуы» дигән төшенчәнең эчтәлеген яңадан карап чыгарга һәм уку-өйрәнү методларының эчтәлеген ачыкларга кирәк. Моны ачыклауда безгә психология фәне ярдәмгә килә.

«Уку-укыту методлары» дигәннән укучының уку-өйрәнү методлары да аңлашыла, диярләр. Нинди методлар? Бәлкем әдәбиятта күрсәтелгән «сөйләү методы» яки «әңгәмә **методы»дыр?** Укучы сөйләве белән укытучы сөйләве — логик яктан да, дидактик яктан да бер үк нәрсә түгеллеге хәзер ачыкланды шикелле. Укытучының китап белән эшләве, мәсәлән, укучының шундый ук «методы»ннан бик нык аерылып торуы һәркемгә билгеле.

Уку-укытуның традицион (элекке) методлары укытучының конкрет субъектка (фәләнгә) йогынты ясавын чагылдырмыйлар. Тормышта, педагогик чынбарлыкта, диалектик үзара бәйләнештә булган ике процесс бар. Әмма алар бер үк вакытта мөстәкыйль ике процесс булып та торалар. Болар: өйрәтү процессы һәм өйрәнү процессы. Алар максатлары белән генә түгел, бәлки укытучының һәм укучының гамәл, эш методлары белән дә бер-берсеннән аерылалар.

Шунлыктан сүз «Уку-укыту методлары» тирәсендә гомумән түгел, бәлки өйрәтү (укыту) методлары белән өйрәнү (уку) методлары тирәсендә конкрет барырга тиеш.

«Уку-укыту методлары» дигән төшенчә үзенең традицион мәгънәсе белән дә, бүген кулланыла торган мәгънәсе белән дә алдынгы укытучыларның әһәмиятле казанышы булган педагогик тасавыр принцибын чагылдырмый. Бу принципның асылы шунда: укытучы үз укучыларының танып-белү эшчәнлеге процессын да, нәтиҗәсен дә алдан ук күрергә тиеш. Шушы принципка туры китереп, укытучы дәрес өчен кирәкле укыту материалын алдан әзерли. Укучыларның белем алу өчен кирәкле өн-рәнү алымнарын һәм методларын алдан ук күздә тотып, үзенең дәрес бирү алымнарын һәм методларын сайлый. Икенче төрле әйткәндә, укытучының гамәл

(действие) методларында, гүяки, укучыларның танып-белү гамәлләре программалаша, өйрәтү (укыту) методы укытучыга укучыларның эшчәнлеге белән идарә итәргә мөмкинлек бирә.

Хәзер инде «Өйрәтү һәм өйрәнү алымнары» дигән төшенчәләр нәрсәне аңлатуга тукталыйк. Ул, башлыча, күзәтелә һәм эчтәлеген укыту материалы тәшкил итз> торган бертөрдәге шартлы педагогик гамәлләрне (действия) аңлата. Сөйләү, текст уку, тасвирлау, биремнәр төзү, аңлату, тәҗрибә ясау, сорашу, мәсьәлә бирү һ. б.— болар барсы да укытучының эш алымнарына керәләр. Аларны метод белән бутарга ярамый. Укытучы дәрес материалым аңлатканда, укыту алымнары кулланып, укучыларга тышкы яктан тәэсир ясый, икенче төрле әйтсәк, балаларда белем алырга омтылыш уята. Бу — өйрәтү (укыту) алымының төп билгесен тәшкил итә. Өйрәтү алымнарының үзара төрле мөнәсәбәттә кушылуыннан теге яки бу өйрәтү (укыту) методы барлыкка килергә мөмкин.

Укучының уку-өйрәнү эше алымнары да шушы ук принциптан чыгып билгеләнә. Сөйләп бирү, фактларны тасвирлау, биремнәр үтәү, мәсьәләне тәгъбирләү яки фараз <итү, күзәтү, текст өстендә эшләү, диктант яки инша (изложение) язу, тәҗрибә ясау, модельләр төзү (конструкцияләү), мәсьәләләр яки мисаллар чишү, чагыштыру һ. б.— болар барсы да укучының уку-өйрәнү эше алымнары. Өйрәнү алымнарының төп билгесе — укучының белемнәрне үзләштергәндәге тышкы хәрәкәтләре яки уку-танып-белү эшчәнлегенең ысуллары: әйтик, мәсьәләнең шартын һәм аның чишелешен язу, укытучы ясый торган тәҗрибә-яе күзәтү һ. б.

Өйрәнү алымнарының үзара мөнәсәбәттә кушылуыннан теге яки бу уку-өйрәнү методы барлыкка килә. Ул, башлыча, эчке билгеләр белән характерлана. Мәсәлән: әгәр укучы күнекмә мәсьәләне (чишү юлын укытучы алдан күрсәткән була) яза алса (2 + 6 = 8), бу белемнәрне репродуктив (хәтергә төшерү юлы белән) үзләштерү акты, әгәр элек таныш булмаган чишү юлын укытучы җитәкчелегендә ул үзе тапса (x + 6 = 9), монсы инде, гәрчә укучының тышкы гамәле бер төсле үк күренсә дә, иҗади үзләштерү акты була.

Методлар — фактларны гади санап чыгу гына түгел, алар эштә кулланма булып торалар. Проблемалы уку-укыту күзлегеннән методларга билгеләмә биргәндә түбәндәге таләпләр куела:

Беренчедән, уку-укыту методларына билгеләмә бирүнең һәм аларны классификацияләүнең нигезендә «белем чыганагы» гына түгел, бәлки : 1) педагогик тасавыр, 2) укучының танып-белү мөстәкыйльлеге дәрәҗәсе, 3) фәнни тикшеренү методлары белән элемтә һәм 4) уку-укыту процессының идарә ителү принциплары

ята.

Икенчедән, укытуда ике төрле конкрет эшчәнлек процессы булганлыктан, укытучы эшчәнлеге методлары белән укучы эшчән-леге методлары булу да шарт. Бу методлар өйрәтү системасы алымнарыннан һәм өйрәнү системасы алымнарыннан гыйбарәт.

Өченчедән, проблемалы өйрәнү методлары укучының кайбер фәнни тикшеренү алымнары һәм методларыннан файдалану (күзәтү, аналогия ясау, гипотеза кую, фикри эксперимент һ. б. ш.) һәм өйрәтү методлары белән тыгыз бәйләнештә булу дигән сүз. Өйрәтү методлары исә укучының белемнәрне үзләштерүенең һәм үсе-шенең психологик-дидактик закончалыкларын искә алып төзеләләр.

Татарстан мәктәпләрендә уку-укыту процессын оештыру тәҗрибәсенә анализ ясау һәм өйрәнү (уку) эшенең закончалыкларын файдалану нигезендә, дәрестә яңа материал узганда укытучылар һәм укучылар куллана торган түбәндәге методларны аерып күрсәтергә мөмкин.

А) **Укытуның ятлату** (информационно-сообщающий) **методы.** Бу метод белән дәрес биргәндә укытучы барлык өйрәнү материалын укучыларга әзер нәтиҗәләр, әзер кагыйдәләр, законнар, теоремалар формасында гади бәян итү, сөйләп бирү, хәбәр итү юлы белән җиткерә. Әлеге метод проблемалы укытуга китерми, чөнки ул уку-өйрәнүдә:

**а)догматик** (аңламыйча ятлау, бикләү) **метод** хасил итә. Ятлату методы белән укытканда укытучы сөйләгәнне укучылар пассив рәвештә тыңлап кына утыралар, укыту материалын ятлап кына алалар, аны күп тапкырлар кабатлыйлар, бикliләр. Дәрес материалын аңлап үзләштермәү —
догматик өйрәнү методының асылы. Шунлыктан ул проблемалы укытуның капма-каршысы булып тора.

Б) **Аңлату-күрсәтү** (объяснительно-иллюстративный) **методы.** Бу укыту-өйрәтү методы — совет педагогикасының үткәндәге казанышы. Укытучы класска фән ачкан нәтиҗәләрне хәбәр итеп кенә калмый, бәлки законнарның, кагыйдәләрнең асылын да аңлата, дәрес барышында төрле төрдәге күрсәтмә әсбаплардан файдалана, үзенең сөйләмен күрсәтмәлелек белән бәйләп алып бара. Бу метод белән укытканда, өйрәткәндә, гадәттә, укучыларның репродуктив (хәтергә төшерү) типтагы мөстәкыйль эшләре күбрәк урын ала.

б)**Укучының хәтерләү** (аңлап ятлау) **методы** (репродуктивный метод) укытучының аңлату-күрсәтү методын кулланудан килеп чыга. Төп

төшенчәләрне укучы аңлап үзләштерә, ләкин, кагыйдә буларак, аларны яңа белемнәрне мөстәкыйль рәвештә үзләштергәндә файдалана белми. Укучының танып-белү эшчәнлеге мөстәкыйльлеге дәрәҗәсе түбән, даими актив фикерләү процессы юк.

В) **Белдерү-дәртләндерү** (информационно-побуждающий) **методы** укытуның аңлату-күрсәтү методын иҗади үстерү нәтиҗәсе булып тора. Бирелә укытучы өйрәнү материалының бер өлешен үзе бәян итә, ә икенче өлешен проблемалы сораулар һәм танып-белү мәсьәләләре итеп тәгъбирли. Биремнәр биреп һәм сораулар куеп, укытучы укучыларны мөстәкыйль эшләр үтәргә яки аларда сорауларга җавап эзләргә (фикери эзләнү) дәрт уята. Бу метод проблемалы укуга алып бара, чөнки ул:

в)**өлешчә-эзләнү** (частично-поисковый) **өйрәтү методы.** Өлешчә-эзләнү методы белән дәрес биргәндә, укучы укытучының бәян итүен пассив кабул итми, бәлки класс алдына куелган мәсьәләләрне анализлауда һәм чишүдә ул үзе дә катнаша, ягъни, элек алган белемнәре һәм күнекмәләреннән иҗади файдаланып, өлешчә үзе гомумиләштерә һәм нәтиҗәләр ясый. Яңа белемнәрне ул үзенең зиһенен эшләтеп кенә алмый, бәлки фикери эзләнү, мөстәкыйль танып-белү эшчәнлеге нәтиҗәсендә дә ала.

г) **Дәртләндерү** (побуждающий) **өйрәтү методы** кулланганда, укытучы укучыларга белемне гади юл белән җиткерми, бәлки иҗади типтагы мөстәкыйль эшләр бирә, ягъни класска сораулар, мәсьәләләр, биремнәр бирә һәм укучыларны мөстәкыйль танып-белү эшчәнлегенә дәртләндерә. Бу укучыны:г) яңа белемнәр үзләштергәндә **тикшеренү методы** (исследовательский метод) куллануга китерә. Аның асылы шуннан гыйбарәт: укучы укыту биремнәрен практик үтәү барышында фикри читенлеккә дучар була, проблемалы ситуацияне анализлый, проблеманы тәгъбирли һәм хәл итә (ягъни танып-белү процессының барлык этапларын, баскычларын уза). Проблеманы хәл итү өчен җитеп бетмәгән информацияне (хәбәрне) укучы үзе эзләп таба, аңа анализ ясый, бу укучыга үзе куйган гипотезаны нигезләргә һәм исбатларга мөмкинлек тудыра.

Методларга без биргән билгеләмәләр һәм аларны классификацияләү бәхәсле булырга мөмкин. Ләкин без проблемалы уку-укыту процессына туры килә торган, укытучы белергә һәм иҗади кулланырга тиешле төп өйрәтү һәм өйрәнү методларын шулай күз алдына китерәбез. Бу шактый катлаулы мәсьәлә һәм шунлыктан ул фәнни-тикшеренү эшләрен дәвам иттерүне, күпләгән мәктәпләр практикасында

сынап карауны таләп итә.

## ПРОБЛЕМАЛЫ УКУ-УКЫТУ ПРОЦЕССЫН ОЕШТЫРУ ЫСУЛЛАРЫ

Мәктәп баласының уку-өйрәнү эшен оештыру буенча укытучының барлык эш-чәнлеге, башлыча, я укучыларга фәннең нәтиҗәләрен, законнарны, кагыйдәләрне һ. б. әзер килеш җиткерү, яки шушы законнарның, теоремаларның, кагыйдәләрнең асылын ачуга аларның мөстәкыйль эшчән-леген юнәлтү белән билгеләнә. Шуңа туры китереп, проблемалы уку-укыту процессын оештыруның ике принцибы турында сүз алып барырга мөмкин. Алар:

а) өйрәнү материалын проблемалы бәян итү һәм

б) укучыларның мөстәкыйль эшләрен оештыру принциплары.

Уку-укыту процессын оештыруның нигезендә шушы ике принципның үзара бергә бәйләнеп, үрелеп баруы ята. Бу бәйләнеш, бер үк вакытта проблемалы уку-укытуның дәрәҗәсе булып, уку-укыту процессын оештыруның **алты ысулы** (төре) ярдәмендә тормышка ашырыла:

1) Проблемалы бәян итүнең I төре.
2) Проблемалы бәян итүнең II төре.
3) Проблемалы бәян итүнең 111 төре.
4) Мәсьәлә-әңгәмә системасы.
5) Программалаштырылган биремнәр системасы.
6) Тикшеренү биремнәре системасы.

Бу ысуллар укытучының дәрес барышында төрле методлар куллануы нәтиҗә-сендә барлыкка киләләр. Берәр методның өстенлек алуы теге яки бу ысулны хасил итә. Мәсәлән, ятлату методын гына куллану проблемалы уку-укытуны оештыруның бер ысулына да китерми.

Уку-укыту процессын оештыруның теге яки бу ысулын сайлау өйрәтү методларына гына түгел, бәлки дидактик максатларга, уку материалының эчтәлегенә, укучыларның белем ала белү осталыгына да бәйле.

Проблемалы уку-укытуны оештыруга бәйле әлеге ысулларның проблемалы булмаган, хәбәр итү (информацион) ысулы белән чагыштырганда төп үзенчәлекләре нәрсәдә?

## I. УКЫТУЧЫНЫҢ УКУ МАТЕРИАЛЫН БӘЯН ИТҮЕ ТУРЫНДА

### 1. Укытучының информацион бәян итүе.

Яңа белемнәрне укучыларга традицион типта җиткерүнең, ягъни уку материалын

информацион бәян итүнең асылы нидән гыйбарәт? Әйтергә кирәк, гомуми белем мәктәпләре укытучылары, аеруча гуманитар предметлар укытучылары, уку материалын укучыларга, нигездә, информацион бәян итәләр бит, ягъни аңлатыр-аңлатмас кына сөйләп бирәләр.

Дидактика буенча кулланмаларның һәм хосусый методикаларның барсында да диярлек, укытучы яңа материалны укучыларга җиткергәндә: сөйли, аңлата, күрсәтә, ә укучылар исә әлеге белемнәрне аңлы рәвештә кабул итәләр һәм ятлыйлар, диелә. Бу очракта укучыларның танып-белү эшчәнлегенә урын калмый. Дәрес материалын менә шулай укучыга җиткерү информацион бәян итү була инде. Информацион бәян итү кешенең фикери эшчәнлеген, фикерләү сәләтен үстерүгә китерерлек дәрәҗәдә активлаштыра алмый.

Аннан да бигрәк, информацион бәян итү вакытында теге яки бу фактның, күренешнең, төшенчәнең билгеләре һәм үзенчәлекләре еш кына тасвирлау характерын ала. Мондый очракта укучылар дәрес материалының асылына төшенеп җитми калалар.

Мәсәлән, IX класста «РСДРПның III съезды Россиядә революциянең характеры, хәрәкәткә китерүче көчләре һәм перспективалары турында» дигән тема өйрәнелә. Укытучы революциянең ни өчен буржуаз-демократик булуын информацион бәян итә. Революциянең максатларына, хәрәкәткә китерүче көчләренә һәм көрәш методларына туктала. Революциянең гегемоны турындагы мәсьәләне ачыклап, укытучы ни өчен пролетариатның гегемон булырга тиешлеген әйтә һ. б. Укытучының бәян итүе тулы һәм дөрес булса да, дәлилсез һәм шунлыктан ул укучыларны активлаштырмый.

Мондый метод белән бәян иткәндә, укучылар большевиклар тактикасының асылын үзләштерә алмыйлар. Россиядә башланган революция ни өчен буржуаз характерда булырга тиеш? Аның максаты ни өчен патша самодержавиесен бетерү, крепостнойлык калдыкларын юк итү? Ни өчен туры-дан-туры программа-максимумны үтәү, ягъни капитализмны бәреп төшерү һәм пролетариат диктатурасы урнаштыру мөмкин түгел иде? кебек сораулар бирсәң, еш кына алар аптырашта калалар.

Әлеге материалның кирәгенчә үзләштерелмәү сәбәпләренең берсе шунда, информацион бәян итү вакытында яңа төшенчәләрнең каршылыклы характерда булуы ачылмый, укытучы укучыларның игътибарын шул төшенчәләрдәге объектив каршылыкларга юнәлдерми. Укытучының очраклы рәвештә бирелгән риторик сораулары кай арада проблемалы ситуация тудырсалар да, укучыларның

уй-фикерләре уянмый, башлары кирәгенчә эшләми. Чөнки әлеге сорауларга укытучы үзе үк җавап биреп бара. Мондый кимчелек проблемалы бәян иткәндә гадәттә булмый.

**2. Проблемалы бәян итү.** Белемнәрне проблемалы бәян итү нәрсәгә бәйле соң? Беренче нәүбәттә, ул яңа белемнәрне җиткерү барышында укытучының класс алдына сораулар куюы белән бәйле. Укытучылар элек тә сораулар куялар иде, куюын. Аңлату методына, ди, мәсәлән, күренекле ди-дакт М. Данилов, «күптәннән үк эвристик әңгәмә килеп кушылды, ул яңа белемнәрне өйрәнгәндә укучыларны беркадәр активлаштырырга мөмкинлек бирде. Әмма аны куллану шартлары бик чикле иде».

Проблемалы бәян итүнең төп билгеләре түбәндәгеләр: дәрес барышында проблемалы ситуацияләр тудырыла, укучылар әлеге ситуацияләрне анализлыйлар һәм проблеманы тәгъбирләү буенча мөстәкыйль эшләр башкаралар, укытучы куйган проблеманы хәл итү ысулларын табу буенча эзләнүләр алып баралар.

Укытучының белемнәрне проблемалы бәян итүенең асылы түбәндәгеләрдән гыйбарәт: укытучы дәрес материалының билгеле бер өлешен генә классқа аңлатып бирә, икенче өлешен (өйрәнелә торган күренешләрнең билгеләрен, үзенчәлекләрен һәм алар арасындагы бәйләнешне) ул класс алдына проблемалы сораулар һәм танып-белү мәсьәләләре формасында куя. Укучылар аларны укытучы ярдәмендә һәм аның җитәкчелегендә мөстәкыйль рәвештә үзләре үзләштерәләр. Проблемалы ситуацияләр яңа материалны өйрәнү барышында тудырыла, әмма проблемаларны хәл итү юлын укытучы барлык очракларда да күрсәтми.

Проблемалы ситуациянең информацион бәян иткәндә дә тудырылуы мөмкин, билгеле. Әмма эш шунда, информацион бәян иткәндә проблемалы ситуация очраклы, стихияле рәвештә, уку-укыту процессының логикасы буенча гына туа.

Проблемалы бәян иткәндә исә ситуация читенлеге укытучы тарафыннан, укучыларның танып-белү эшчәнлеге белән идарә итү чарасы буларак, алдан уйлап, алдан хәзерләнеп барлыкка китерелә. Проблемалы бәян итү белән проблемасыз бәян итү арасында төп аерма шунда, беренче очракта укучы ситуацияне анализларга һәм төп сорауны тәгъбирләргә тырыша, икенче очракта исә андый гамәлләр юк.

Проблемалы бәян итү үзенең структурасы һәм укучыларның танып-белү эшчән-легенең дәрәҗәсе буенча бертөрле генә булмый. Проблемалылыкның дәрәҗәсенә бәйле рәвештә (моңардан, башлыча, сорауларның, мәсьәләләрнең,

биремнәрнең катлаулылык һәм укучының проблеманы мөстәкыйль рәвештә хәл итә белү дәрәҗәсе аңлашыла) проблемалы бәян итүнең өч төрен аерып күрсәтергә мөмкин.

**1) Проблемалы бәян итүнең беренче төре.** Бәян итү процессында укытучының эшчәнлеге информацион һәм проблемалы сораулар тезмәсе булдыру һәм проблемалы ситуацияләр тудыру белән характерлана. Дөрес, укытучы барлык материалны үзе бәян итә, ләкин шул ук вакытта ул укучыларга проблемалы ситуациягә анализ ысулларын һәм проблеманы тәгъбирләү юлларын күрсәтә. Укытучы үзе куйган сорауларга үзе үк җавап бирсә дә, нәтиҗәләрне класска әзер килеш җиткерсә дә, укучыларның дәрес материалы белән кызыксынулары көчәя һәм аларда азмы-күпме мөстәкыйль танып-белү эшчәнлеге билгеләре барлыкка килә. Мәсәлән, класска инде безгә таныш булган: «Ни өчен рус буржуаз-демократик революциясендә пролетариат гегемон булырга тиеш?» дигән сорау бирелде, ди.

Укучылар башта бу сорауга җавап бирергә кыенсыналар. Берәүләре, чөнки эшчеләр күпчелек тәшкил итә; икенчеләре, чөнки эшчеләр дәүләтнең демократик төзелешен телиләр, дип җавап бирәләр.

Укучыларга үз фикерләрен әйтергә ирек биреп (аларның әлеге сорауга дөрес җавап бирә алмауларын төшенүләре әһәмиятле), пролетариатның иң революцион сыйныф икәнен, рус буржуаз-демократик революциясенең буржуазиягә генә түгел, пролетариатка да файдалы булуын укытучы үзе аңлата.

Мондый төрдәге проблемалы бәян итүне оештыру өчен, өйрәтүнең нинди методларын кулланырга кирәк? Практика күрсәткәнчә, биредә, кагыйдә буларак, проблемалы сораулар белән аңлату-күрсәтү методы кулланыла. Укытучы кай арада укучыларга мөстәкыйль эшләр дә биргәли. Ләкин алар, һәрвакытта да диярлек, элек өйрәнелгән кагыйдәләрне (законнарны, теоремаларны) яки күнекмәләрне куллану буенча укучыларның хәтерләү эшчәнлеген генә таләп итәләр.

Шуны әйтергә кирәк, мөстәкыйль эшләр проблемалы бәян итүнең бөтен төрләрендә дә башкарылалар, хәтерләү һәм иҗади характерда булалар. Шулай да, әгәр проблемалы бәян итүнең беренче төрендә иҗади характердагы мөстәкыйль эшләр сирәк бирелсәләр, икенче һәм өченче төрләрендә исә алар даими урын ала. Проблемалы бәян итүне традицион бәян итүдән аерып торучы дидактик билгеләрнең берсе әнә шул.

Проблемалы бәян итүнең беренче төре, нәтиҗәсе азрак булса да, укытучы өчен

иң җиңеле. Ул күбрәк проблемалы уку-укыту күнекмәләренә укучылар ия булмаганда яки уку материалы шуны таләп иткәндә кулланыла.

Проблемалы бәян итүнең беренче төре, уку материалы белән кызыксыну арттырса да, укучыларда иҗади үзләштерү күнекмәләре тәрбияләми. Укучыларда программа материалын иҗади үзләштерү күнекмәләре хасил итү, формалаштыру бурычын проблемалы бәян итүнең икенче төре уңышлы үти.

**2) Проблемалы бәян итүнең икенче төре** — алдан уйланылган информацион һәм проблемалы сораулар системасы булу, шулай ук сүз һәм күрсәтмәлелекнең үзара бәйләнеп баруы белән характерлы. Материал өлешләргә бүленә, аларның һәркай-сында проблемалы ситуация тудырыла. Күбрәк аңлату-күрсәтү методы белән өйрәтеп, укытучы фактик материалга анализ һәм гомумиләштерү ясауга укучыларны да-тарта.

Проблемалы бәян итүнең икенче төренең теп эчтәлеге, аның төп билгесе шунда, укытучы фән тарихында галимнәр куйган мәсьәләләрне тикшеренү логикасын, ягъни фәнни ачышларның ничек ясалуын күрсәтә. Шундый фәнни аңлатуның классик мисалын М. Н, Скаткин дидактика буенча үзенең бер лекциясендә китергән иде. Бу мисал К. А. Тимирязевның үсемлекләр тормышы турында халык алдында ясаган бер лекциясеннән алынган.

«Үсемлекнең үсү күренеше турындагы күзәтүебезне,— ди; бөек галим,— шыткан орлыктан тамыр һәм сабак чыга башлаган, аларның берсе яктылыктан качкан кебек җиргә яшеренә, икенчесе, киресенчә, яктылыкка, һавага омтыла башлаган вакыттан алыйк. Бу күренешне күзәткән вакытта табигый рәвештә уйга килергә тиеш булган беренче сорау: ни өчен тамыр белән сабак бер-берсенә капма-каршы якка таба, беренчесе — җиргә, икенчесе — һавага, берсе түбәнгә таба, икенчесе өскә, югарыга таба үсә башлыйлар?»

Сорауны әнә шулай кую, тыңлаучыларны конкрет проблема (каршылык) алдына китереп бастыра: проблемалы ситуация туа. Әгәр галим үзенең соравына шундук җавап биргән, ягъни фактны шундук фәнни аңлаткан булса, тыңлаучылар моны аңлаган, бер үк үсемлекнең ике органының төрле юнәлештә үсү сәбәбен хәтерләрендә калдырган да булырлар иде. Бу информацион бәян итү булган булыр иде. Әмма К. А. Тимирязев башка метод куллана, ул фән ачкан хакыйкатьне шундук әйтеп бирми, тыңлаучыларга галимнәрнең бу ачышка ничек, нинди юллар белән килүләре турында сөйли башлый:

«Әлеге сорау,— дип дәвам итә ул,— галимнәрне күп кенә читенлекләр алдына китереп куя... Бу күренешнең сәбәбен эзләгәндә, табигый ки, галимнәр яктылыкка

һәм туфракның дымына игътибар итәләр. Әгәр сабаклар яктылыкка сузылалар, ә тамырлар яктылыктан качалар икән, димәк, үсү юнәлешен билгеләүче сәбәп яктылык, аның тышкы көче».

Биредә без югарыда куелган проблеманы чишү юлында беренче фараз итүне, башлангыч гипотезаны күрәбез. Әмма ул гипотеза дөреслеккә туры килми, шунлыктан галим үзенең тыңлаучыларына гипотезаны кире кагучы тәҗрибәләр турында хәбәр итә:

«Әмма,— ди ул,— бу карашның дөрес булмавын исбатлау читенлек тудырмый. Шытым дөм караңгыга урнаштырылган шартларда да үсемлекнең органнары үз юнәлешләрендә үсәләр; алай гына да түгел, әгәр орлыкны иләккә утыртсаң һәм, яктылык түбәннән төшәрлек итеп, аны тәрәзә өстенә асып куйсаң да, тамырлар барыбер иләктәге туфрак катламын тишеп, түбәнгә, яктылыкка таба үскәндә, сабаклар, киресенчә, югарыга, ягъни яктылык булмаган якка таба омтылалар. Икенче фараз итү, ягъни, тамырлар дымлы туфракка таба үсәләр, дип уйлау икенче тәҗрибә белән, ягъни шытучы орлыкны төрле яктан дымлы туфракка күмеп карау белән кире кагыла. Бу очракта да тамыр да, сабак та капма-каршы якка үсәләр. Шулай итеп, тамыр да, сабак та яктылыкка карата да, дымлылыкка карата да даими торышта түгелләр, аларның торышы горизонтка карата гына даими икән: тамыр һәрвакыт түбәнгә, сабак — югарыга таба үсә... Менә бу хәл үзе генә дә, аларның болай үсүенә авырлык көче, ягъни планетабызның тарту көче тәэсир итә, дигән фикергә этәрергә тиеш».

Беренче фараз итүне инкарь итүче тәҗрибәләр турында сөйләп, галим тыңлаучыларын логик рәвештә яңа гипотеза алдына куя, ягъни, проблеманы хәл итүне җирнең тарту көченнән эзләргә кирәк, дигән фикергә китерә. Ләкин моны шулай ук исбатларга кирәк:

«Без моны,— ди К. А. Тимирязев,— эксперимент юлы белән исбат итәргә тиешбез. Әгәр тамыр белән сабак үсешенең юнәлешләре авырлык көченә бәйле икән, бу көчне читләштереп, без әлеге күренешне юкка чыгарабыз, көчнең тәэсир итүен йомшартып, күренешне дә йомшартабыз: ниһаять, бу көчне, башка юнәлештә хәрәкәт итүче икенче көч белән алыштырып, күренешне дә үзгәртәбез. Эшне нидән башларга? Әйтик, җир өстендәге берәр әйбергә җир шарының тарту тәэсирен ничек булдырмаска? Үсемлек өчен ас һәм өснең булмавына ничек ирешергә? Без моны бөтенләй үк юк итә алмыйбыз, алуын. Шулай да бу көчне кыска бер вакыт эчендә капма-каршы юнәлештә хәрәкәт иттерә, аларның хәрәкәтен үзара тигезли һәм, шул юл белән, җирнең тарту көчен озаграк вакытка да юкка чыгарып тора

алабыз.

Моның өчен шыткан орлыкны әйләнүче тәгәрмәчнең тугымына беркетәбез дә, тәгәрмәчне кечкенә электромагнит двигатель белән хәрәкәткә китерәбез... Шундый шартларда ясалган тәҗрибә тамыр белән сабак нинди хәлгә куелсалар да үзләре беркетелгән торышны саклап калуларын күрсәтә» (К. А. Тимирязев. Жизнь растений. М., 1908, 173—174 нче бит).

Шулай итеп, галим, фәнни фикерләү юлын күрсәтеп, үзенең тыңлаучыларын «Фикерләүнең хакыйкатькә таба диалектик хәрәкәтен күзәтергә» мәҗбүр итә, гүя фәнни эзләнү процессында алар үзләре катнашалар» (М. Н. Скаткин).

Проблемалы бәян итүнең икенче төрен кулланып, укучыларны танып-белү эшчән-леген активлаштыру һәм аларның логик дөрес фикерләвенә ирешү өчен, укытучы да әнә шулай эшләргә тиеш. Төрле предмет укытучылары, мәсәлән, уку материалының эчтәлегенә бәйле рәвештә, теге яки бу фәнни ачышның, уйлап табуның тарихы турында сөйләп кенә калмаска, бәлки тәҗрибә, эксперимент, вакыйгаларны тасвирлау, аларның асылына анализ ясау һ. б. ысуллар белән укучыларга хакыйкатькә бару юлын ышандырырлык итеп күрсәтергә бурычлылар.

Укучыларның эшчәнлеге уку материалына кызыксыну көчәю белән генә түгел, бәлки бәян итүнең логик үрнәген (фән тарихында проблеманы хәл итү) актив үзләштерү, бу үрнәккә иярү, проблеманы тәгъбирләргә тырышу һәм аны мөстәкыйль хәл итү белән дә характерлана. Белемнәр үрнәк буенча да, үзлекләреннән мөстәкыйль эшләр башкарганда да үзләштерелә. Ләкин проблемалы уку-укытуның икенче төрендә аңлатып бирүнең өлеше зуррак, ә укучыларның мөстәкыйльлеге әле тулы түгел. Әмма логик фикерләүнең нәтиҗәле алымнары укучылар үзләре эшләгәндә, ягъни кирәкле фикерләү операцияләрен үзләре башкарганда гына була ала.

Проблемалы бәян итүнең икенче төре, кагыйдә буларак, аңлату-күрсәтү методы проблемалы сораулар кую, тәҗрибә ясау һ. б. алымнар белән чиратлашу ярдәмендә генә оештырыла.

**3) Проблемалы бәян итүнең өченче төре** икенче төреннән информацион һәм проблемалы сораулар системасы булу белән генә түгел, бәлки укучыларның кечкенә-кечкенә иҗади мөстәкыйль эшләрен оештыру (аерым танып-белү мәсьәләләре һәм укыту биремнәре булу) белән дә аерыла. Биредә, кагыйдә буларак, өлешчә-эзләнү методын хасил итә, тудыра торган белдерү-дәртләндерү өйрәтү методы кулланыла. Укучылар хакыйкатькә юлны укытучы белән бергә эзлиләр.

Материалның бер өлешен укытучы үзе аңлата, икенче өлешен беркадәр генә хәбәр итә. Проблемалы ситуация тудырып, ул укучыларның эшчәнлеген фактик (аңлатылмаган, тик хәбәр генә ителгән) материалны анализлауга, мөстәкыйль рәвештә гомумиләштерүгә һәм нәтиҗәләр чыгаруга юнәлдерә. Укытучының сораулары шактый катлаулана төшә. Мәсәлән:

— Ни өчен революция алдында программа-минимумны тормышка ашыру бурычы торган?

— Ни өчен программа-максимумны тормышка ашыру бурычын башта ук куеп булмаган?

— Ни өчен феодализм калдыкларын бетерү белән бер үк вакытта капитализмны да бетерү мөмкин түгел иде?

Болар укучылар өчен проблемалы сораулар: беренче этапта революциянең буржуаз характерда гына була алуын исбат итәргә кирәк. Шунлыктан укучыларның эш-чәнлеге дә материалның шактый өлешен үзләштерүдә фикери эзләнү процессын активлаштыру белән характерлана. Алар укытучы куйган проблеманы үзләре тәгъбирлиләр.

Мәсәлән, укытучы ике төрле фикер тәгъбирләп проблемалы ситуация тудыра:

«Бу революциянең гегемоны пролетариат булырга тиеш». Ни өчен? — ди ул. Менә шушы ике төрле раслау укучыларны читенлек алдына куя. Бераз уйлаганнан соң, алар бу читенлекнең асылын, ягъни проблеманы тәгъбирлиләр:

— Буржуаз-демократик революциянең бер үк вакытта буржуазия өчен дә, про-летарит өчен дә файдалы булуы мөм-кинме?

Алга таба күп кенә фараз итүләр (аларның типлары: промышленность буржуазиясенең үсүе эшчеләр сыйныфы сафларының да үсүе дигән сүз һ. б. ш.) була һәм мөстәкыйль рәвештә (укытучы җитәкчелегендә), буржуаз-демократик революциядә (аның гегемоны булырга тиешле) пролетариат ота, дигән нәтиҗә ясала.

Проблеманы тәгъбирләүнең башка төрле вариантлары да булырга мөмкин. Мәсәлән:

— Буржуаз революция буржуазия өчен генә файдалымы? Революция җиңүдән пролетариат нәрсә дә булса отармы?

Проблема куеп, укучылар аны хәл итүнең юлларын эзлиләр, аларның җаваплары төрле-төрле була: «Әйе, буржуаз революция пролетариат өчен файдалы түгел, чөнки власть буржуазия кулында кала». «Буржуаз революция

буржуазия өчен дә, пролетариат өчен дә файдалы, чөнки буржуазиянең үсүе феодализм калдыкларын бетерә, промышленностьның үсүенә китерә, эшчеләр сыйныфының үсүе һәм көчәюе өчен шартлар тудыра», диләр икенчеләре һ. б.

Проблемалы бәян итүнең өченче төре укучыларның танып-белү мөстәкыйльлеген үстерүдә беренче һәм икенче төрләргә караганда күбрәк файда бирә. Төрле предметларны укытуның алымнары да төрлечә булуы мөмкин. Әмма аның асылы һәрвакыт бер: укытучы дәрес материалының бөтенесен дә үзе аңлатмый, бер өлешен генә аңлатып, укучыларның үзләренә уйларга, билгеле булмаганны үзләренә эзләп табарга мөмкинлек калдыра. Дәрес материалын бәян итү барышында проблемалы сораулар һәм танып-белү мәсьәләләре куеп, укытучы укучыларга проблеманы мөстәкыйль рәвештә тәгъбирләү өчен шартлар тудыра, аларның фараз итүләренә, гипотезалар китерүләренә кайчакта проблеманы үзләре үк хәл итүнең юлларын эзләүләренә җитәкчелек итә.

**Шулай итеп,** дәрес материалын укытучының проблемалы бәян итүенең гадәти информацион бәян итү белән чагыштырганда өстенлеге нәрсәдә икән?

**Беренчедән,** ул укучыларның фикерләү эшчәнлеген активлаштыра, аларның башлангыч мөстәкыйльлеге формалашу өчен шартлар тудыра. Нигезле итеп, исбатлап аңлату укучы үзләштергән белемнәрнең ныклы һәм тирән булуын тәэмин итә, бу, үз нәүбәтендә, белемнәрнең коммунистик иинануга әйләнүенә ярдәм итә. Яңа белемнәрне үзләштерү процессында эталон (ягъни фәнни тикшеренү алымнарын) куллану укучыларның фикерләү сәләте формалашуга китерә.

**Икенчедән,** проблемалы бәян итү фәнни диалектик фикерли белергә өйрәтә, укучыларга фәнни эзләнүләр өчен эталон (үрнәк— өлге) бирә.

**Өченчедән,** проблемалы бәян итү, проблемалы ситуацияләр тудырылганлыктан һәм уку-укыту процессына көчле эмоцияләр (тойгылар) кушылганлыктан, укучыларның уку материалы белән кызыксынуларын бик нык көчәйтә.

**Нәтиҗә ясап** шуны **әйтергә кирәк,** белемнәрне проблемалы бәян итү төрләре укучыларда мөстәкыйль фикер йөртү эшчәнлеген, осталык (умение) һәм күнекмәләр формалаштыруда (башта үрнәккә ия-реләә, аннары мөстәкыйль эшчәнлек барлыкка килә) дидактик ысуллар булып торалар. Мөстәкыйль фикер йөртү эшчәнлеге формалаштыру укытучы җитәкчелегендә бара һәм моның белән ул үзе идарә итә. Бу этапта материалны укытучы күбрәк үзе аңлата, шунлыктан укучыларның танып-белү мөстәкыйльлеге әле һаман түбән дәрәҗәдә була. Әмма проблемалы бәян итү укучыларны тулы мөстәкыйльлеккә әзерли. Укытучы

тарафыннан дәрес барышында системалы рәвештә тудырыла торган проблемалы ситуацияләр укучыларның фикерләү эшчәнлеген активлаштырып кына калмыйлар, бәлки аларны үзлекләреннән белем алырга кызыксындыру өчен әһәмиятле шартлар да тудыралар.